# Тезмә кушма җөмләләр

# Максат:

1. Тезмә кушма җөмлә турында мәгълүмат бирү;
2. Укучыларның анализ ясау, гомумиләштерү, мөстәкыйль фикерләүләренә ирешү;
3. Укучыларда әдәплелек сыйфатлары тәрбияләү.

# Өй эшен тикшерү

1. Сорауга җавап бирү:

- Бәйләүче чаралардан чыгып, кушма җөмлә нинди төрләргә бүленә?

2. ”Хәрәм малның хәере юк” дигән мәкале буенча фикер алышу.

# Проблемалы ситуация булдыру. Уку мәсьәләсен кую

- Нинди җөмлә тезмә кушма җөмлә дип атала?

(Төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру)

# Дәрескә максат һәм бурычлар кую.
# Дәрес темасын ачыклау

**- Компонентлары үзара тезү юлы белән бәйләнгән җөмлә тезмә кушма җөмлә дип атала.**

**Табышмакларны укы, баш кисәкләрен тап. Һәр табышмакта ничә компонент? Бәйләүче чараларга, тыныш билгеләренә игътибар ит**

- Бар бер үлән чокырда, аны таный сукыр да.
- Башы бер, күзе унике.
- Көмеш тәнле - ите тәмле.

Бәйләүче чараларга, тыныш билгеләренә игътибар

# Таблицаны кара, нәтиҗә яса

| Тезмә кушма җөмлә | |
|---|---|
| Теркәгечсез тезмә кушма җөмлә | Теркәгечле тезмә кушма җөмлә |
| Бүгенге концертта Айгөл җырлый, Марат шигырь сөйли. | Бүгенге концертта Айгөл җырлый, ә Марат шигырь сөйли. |

# Сорауларга җавап бирү

а) Тезмә кушма җөмлә нинди төрләргә бүленә?
б) Теркәгечле тезмә кушма җөмләдә, гади җөмләләрне үзара бәйләп, нинди теркәгечләр килә?
в) Теркәгечсез тезмә кушма җөмләдә, гади җөмләләрне үзара бәйләп, нинди чаралар килә?

# Кушма җөмлә эчендәге гади җөмләләрне бәйләүче чараларны табыгыз, кушма җөмләнең теркәгечлеме,теркәгечсезме икәнен билгеләгез

а) Алсу, елмаеп, сыйныфка килеп керде.
б) Мин әйтергә өлгермәдем, ә ул киенергә дә кереп китте.
в) Ай күрде, кояш алды. (мәкаль)

# Тезмә кушма җөмләләрне тап:

а) Көчле музыка яңгырады да, тамаша башланды.

б) Яңгыр явып торды, шуңа карамастан укучылар барысы да концертка ашыктылар.

в) Яшьләр арасында популяр җырчылар бик күп.

г) Мин кирәкле материалларны Интернеттан эзлим, яисә әнием китапханәдән китап алып кайта.

# Өй эше

1. Теркәгечле яки теркәгечсез тезмә кушма җөмләләргә мисаллар табып язарга.

2. Тезмә кушма җөмләләр кулланып, “Әдәплелек сыйфатлары” дигән темага хикәя төзергә.

**Сез бик акыллы, эшчән, тәрбияле һәм шәфкатьле балалар!**